**Республика Татарстан**
**СОВЕТ**
**ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ЛӘКЕ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

---

КАРАР
2019 елның 22 ноябре № 23

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Дружба авылында 2020 нче елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Советы нигезендә Карар:
1.2020 елда Ләке авыл җирлеге Дружба авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2.Алынган акчаларны түбәндәге оешмаларга юнәлдерергә:
- Дружба авылы зиратын коймалау буенча төзелеш материаллары сатып алу һәм эшләр өчен түләү ;
- Ләке авыл җирлеге үзәк Сабантуена, Питрау бәйрәменә бүләкләр алу.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Дружба авылы, Лесная урамы, 2А адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Ләке авыл җирлеге Советы рәисе Л. И. Шәрипова